## Бөек Ватан сугышы елларында язучы-шагыйрьләрнең фидакарьлеге

Бөек Ватан сугышы чорында, татар язучыларының бер төрле сәяси шартларга куелуы нәтиҗәсендә, шул заманга хас образлар системасы, идея, фикер бертөрлелегенә юлыгасың. Чөнки бу әсәрләрдә күтәрелгән темаларның башкаларныкына охшаш аваздашлыгы күренә. Әсәрләрне бертөрле тематик як берләштерә: төрле милләт вәкилләреннән җыелган армиянең сугышчан һәм рухи бердәмлеген чагылдыру. Күп язучыларыбыз исән кайтып, яңадан әсәрләрен камилләштереп бастыру турында да уйлангандыр. Кызганыч, бу җыентыкка кертелгән әсәр авторлары бүген инде исән түгел. Шулай да, бер үк уй-хыяллар белән янган язучылырыбызның әсәрләре нинди генә уртаклыкларга ия булмасын, шәхси үзенчәлекләрен дә саклый алдылар. Хикәя-очеркларга, язма-истәлекләргә бирелгән исемнәр мәгънәви яктан ачкыч ролен үтиләр. Публицистик алымны реалистик тасвир белән яраштырып, авторлар дошманның ерткыч гамәлләрен фаш итүне төп максат итеп куялар. Чоры нинди булуга карамастан, төп сурәтләү объектыннан читләшмәгәндә генә әдәби әсәрләр, вакыт чиген үтеп, бүгенге буын укучысын сокландырып һәм яшәүгә рухландырып торалар. Күп авторларның әлеге әсәрләре күпмедер дәрәҗәдә үзенең эчке кичерешләренә, шәхси тәҗрибәсенә нигезләнеп язылган һәм беренче заттан алып барыла. Гүя, укучы әсәр герое белән янәшә үзе дә сугыш кырында йөри, шул вакыйгаларда катнаша һәм төп герой кичергән кичерешләрне, тетрәнеп, үз күңеле аша үткәрә. Гомумән, сугыш елларындагы күпчелек бөтен совет әдәбиятындагы кебек, бу чор татар прозасында да иң характерлы үзенчәлек аның героик эчтәлегендә иде. Бу очракта журналистика өлкәсендәге олы абруй Ф.Әгъзамов сүзләре безнең сүзгә куәт бирә: “... Сугыш темасы, сугыш каһарманнары темасы ул һәрвакыт изге булып калачак. Безнең бүгенге тыныч тормышыбыз хакына җаннарын фида кылган, иҗат өчен яратылып та, матур хыяллары өзелгән, мәхәббәтләренә кыраy төшкән чәчкә кебек яшь егет һәм кызларның язмышы, илебез азатлыгы өчен көрәштә үзләренең иң гүзәл

сыйфатларын ачып җибәргән азамат ирләрнең язмышы безнең күңелләребезне һәркайчан җәлеп итәчәк”. Димәк, әсәр геройлары хәл кылырга тиеш булган бу четерекле мәсьәлә бүгенге көн өчен дә әһәмиятле. Бөек Ватан сугышы турындагы очерк, хикәя һәм язма-истәлекләр сугыш михнәт-газаплары белән кино-әдәбият аша гына таныш булган укучыны күп нәрсәгә өйрәтә. Сугыш дигән шомлы сүзнең күңелләрдән җуелганы юк. Ул әле озак еллар күңелдән китмәячәк. Ул хакта әле зиһенне генә түгел, гражданлык хисләрен дә уйнатырлык яңадан-яңа әсәрләр язылачак.

Күренекле прозаик, публицист, тәрҗемәче Афзал Шамов (1901-1990) 1943 нче елның февралендә үзе теләп фронтка китә һәм Бөек Ватан сугышында хәрби газеталарның үзхәбәрчесе булып хезмәт итә, фронт матбугатында күпсанлы хәбәрләр, репортажлар, очерклар язып бастыра. Ватан сугышы чорындагы батырлыклары өчен 1944 елда Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. “Үтәлми калган теләк” очеркында бер төркем “Алга, дошман өстенә” газета хәбәрчеләре корреспондент итеп, үз частьларыннан ерак түгел генә Ф.Кәримне алмакчылар. Әсәрдә хикәяләүче “мин”нең А.Шамов икәнлегенә шик тудырмый. Ләкин аның икенче фронтта булуы аркасында рөхсәт бирмиләр. 1944 елның 9 маенда Ш.Мөдәррискә язган хатында Ф.Кәримнең бу редакциягә киләсе килү теләгенең көчле булуын күрәбез: “Язасы килә, монда аның өчен вакыт бөтенләй юк. Мин әдәби иптәшкә очрау ягыннан уңышсыз булдым...”. Язучы иптәшләрнең күңелләре боек. Әнә мәзәк сөйләргә яратучы И.Гази да кирәкмәгәнгә көлми, шаярмый. Язучы геройлары һәрвакыт рухи аклыкка, күңел дөньясының сафлыгына омтылалар, гаделлек, кешелек сыйфатларының һичшиксез өстенлек алуына өмет итәләр. Эчке кичерешләре, рухи халәтләре табигый, реаль һәм ышандырырлык итеп сурәтләнә. Әдип язучы-яшьләрнең, нәкъ менә мораль җирлектә сынау үтүләрен күрсәтүгә җитди игътибар бирә. Сугыш чыннан да кешенең әхлакый сыйфатлары өчен дә җитди сынау булды.

Язучы-шагыйрь Хәйретдин Мөҗәһитне (1901-1944**)** 1939 нчы елда Беренче Ерак Көнчыгыш армиясенә полк командиры итеп билгелиләр, ә 1941

нче елның май аенда Харьков хәрби округының 789 нчы укчы полк командиры итеп күчерәләр. 1942 нче елнын 7 нче февралендә полк командиры каты яралана, чолганышта калып, дошман кулына эләгә, Дахау лагеренда 1944 нче елның 4 нче сентябрендә полковник Х.Мөҗәй вәхшиләрчә үтерелә. Сугыш тынып торган вакытларда алып барган "Сугыш язмалары"нда язучы дошманның тар-мар ителәчәгенә ышанып, йөрәгеннән чыккан ялкынлы сүзләрне яза: "...Йөрәкнең әллә кайсы җирендә: Җиңәрбезме? – дигән уй тора. Ләкин җиңәрбез! дигән җавап көчлерәк. Чөнки без җиңә алмый торган нәрсә бу дөньяда юк әле һәм буласы да юк". Ут эчендә язылган "Сугыш язмалары" шактый калын. Ул дүрт дәфтәргә бүленгән. Дүртенче дәфтәрдә фашистларның ерткычлыгын нәфрәтләнеп яза: "Урман арасында бер үлек гәүдәгә очрадым ... Немецларны куганда һәлак булган булса кирәк. Әйләндерәм.Уң күзе тирән итеп чокып алынган. Аяк киемнәрен салдырганнар. Күкрәгендә - пычак эзләре. Аркасында – сөягенә кадәр теленгән "йолдыз". Ниндидер "профессор" бер дә ашыкмый гына "операция" ясаган...Бәлки, аның өчен берәр фашист тимер тәре белән бүләкләнергә уйлагандыр. Билгесез сугышчы өстендә канлы эшләр эшләгән фашист та тимер тәрегә ирешә алмый шушы үлекләр арасында ятадыр. ... Һәркемдә үч, һич бетми торган үч кайный!". "Сөт" очеркында авылны немецлар чолгап ала. Ашарга дип кергән немецларга Анна Васильевна кайнап торган сөтне йөзләренә сибә. Ерткычлар өйдәге барлык хатын-кызларны, балаларны аталар. Фашизм, гомумән дә, кешелек сыйфатларыннан мәхрүм, аңа бары тик ерткычлык кына хас, дигән фикер үткәрелә.

Күренекле язучы Гомәр Бәширов (1901-1999) Бөек Ватан сугышы башлангач, яңадан "Совет әдәбияты" журналында җаваплы редактор булып эшли, 1942 елда аңа Татарстан радиокомитетының баш редакторы һәм рәис урынбасары вазифасын йөклиләр. 1942 елда аны Төньяк-Көнбатыш фронтында чыга торган "Ватан өчен" газетасына өч айлык командировкага җибәрәләр. Бай матриалын эшкәртеп, 1943 елда "Гармунчы" исемле җыентыгын чыгара. Татарстанның халык язучысы исемен ала, ТР Г.Тукай

исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. “Көзге ачы җилләрдә” автобиографик повестенда аянычлы хәлләрне искә алганда болай ди : “Мәскәү язучыларының күбесе сугыш елларында Алабуга, Чистай шәһәрендә яшәп торды.....Мәскәү язучыларының өч йөздән артык гаиләсен урнаштыру никадәр генә кыен булмасын, аларның күбесе ике-өч көн эчендә бүлмәле булды” Ә үзебезнекеләргә шинель киеп, карлы-бозлы окопларда ятасылар, ут астына керәселәр бар. Бүтән халыклар белән чагыштырганда, сан буенча иң күп югалту татарда була. Эзтабар Шаһинур Мостафин язганча, сугышта 104 татар язучысы һәм журналисты катнаша, 31е корбан була. Исән кайтканнарының күбесе фронт яраларыннан җәфаланып яши. Сугыш турысындагы өлешендә, тормыш һәм яшәү өчен көрәшү турында фәлсәфи уйларга бирелүләр языла. Һәр бүлегенең кабатланмас эчтәлеге бар. Биредә язучы иман, намус, әдәп-әхлак, яшәү-үлем кебек төшенчәләргә үзенең бәясен биреп бара. Тылдагы матур әдәбиятның сугышчыларга уңай тәэсире сизелә. Бер төркем язучы-шагыйрьләр турында җылы истәлекләр бирелә, алардан килгән хатлардан өзекләр китерелә.

Язучы-прозаик, драматург Абдулла Әхмәт (1905-1976**)** ике ел буе фронтның алгы сызыгында гади солдат булып фашист илбасарларына каршы сугыша; яраланып, госпитальдә дәваланып чыккач, яңадан алгы сызыкка кайта һәм 1943 елдан башлап сугышның ахырына кадәр “Алга, дошман өстенә” исемле татарча фронт газетасы редакциясендә хәрби мөхбир булып хезмәт итә, шунда совет солдатларының батырлыклары турында күп кенә очеркларын, хикәяләрн бастыра. 1952 елда очерк һәм хикәяләре “Солдат хикәяләре” исеме астында аерым китап булып басыла. Фронттагы сугышчан хезмәтләре өчен А.Әхмәт Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә. “Зәңгәр конверт” әсәрендә хат ташучы Таняның алып килгән сөенече тасвирлана. Автор солдатларның үз-үзләренең тотышына игътибарны юнәлтә. Таня туган яктан килгән хатларның кыйммәтен яхшы белә. Кече яшьтән ятим калган старшина Мәҗитов кына хат көтми. Иптәшләренә килгән хатларны укып бераз юану ала. Хат килүгә куанып, шул

арада гурмун тавышын яңгыратып, күңел ачу җаен да табалар. Язучы Мәҗитов, Бикбулатовларның разведкага барып, уңышлы үтүләрен, аларга хас кешелекле характер сыйфатларын тасвирлый. “Рәхмәт яугырлары” хикәясендә хат килү Сәлимә әбинең күпне кичергән йөрәк түрендәге хәсрәтен терелтеп җибәрә. Ул улының үлүе турында кайгылы хәбәр ала, ләкин кайда күмелүе турында хәбәрдар түгел. Әлеге хат аңа ике дистә елга якын булган кайгылы вакыйганы хәтерләтә. Сәлимә карчык Белоруссиянең Городок шәһәренә юл тота. Бу юл - улының ил азатлыгы хакына көрәш юлы да, газизенә илтә торган мәшәкатьле юлы да, татар әбисенең тормыш юлы да булып аңлашыла.

Газиз Иделле (1905-1985) Ватан сугышы елларында берничә ай Беренче Украина фронтында иҗади командировкада булып, “Ватан намусы өчен” исемле фронт газетасында эшли, очерклар, хәбәрләр басып бастыра. “Минзәлә егете” очеркында тупчы һәм командир Салих Гатин үткән юлы сурәтләнә. Ватан алдында торган гражданлык бурычыңны намус белән үтәү, үзеңне дә кызганмау кебек әхлакый җаваплылык кулына корал тоткан кешеләрнең күбесенә хас иде. Язучы персонажларның эчке дөньяларына тирән үтеп кереп һәм әхлакый проблемаларны үзәккә куеп тасвирлый. Аны табигый, реаль һәм ышандырырлык итеп сурәтли. “Коммунистлар” очеркында Сталинград өчен барган сугыш ваыйгалары гәүдәләндерелә. Татарстан егете Мотыйгуллинның сынмас рухы, батырлыгы күрсәтелә. Бу елларда партиягә күп егетләр керә. Курск дугасындагы каты сугышларда да катнаша. Язучы үзенең психологик эволюциясен күзәтүне бала вакыттагы күңел кичерешләреннән башлый. Һәр вакыйгага карата, герой күңелендәге сакланып калган бала вакыттагы самими хисләрне искә алу бәян ителә. Әдәби сурәт тудырганда автор тормыштагы кискен конфликтларны сурәтләп, чорга хас каршылыкларның үсмер геройларга ничек тәэсир итүен, анда ничек итеп ныклы характер формалашуын күрсәтә. Билгеле, бу материаллар автор тарафыннан сайланып алыналар һәм, кирәк икән, уйлап чыгаруга да урын бирелә.

Шагыйрь, прозаик, драматург Салих Баттал **(**1905-1995**)** Хәрби һава көчләренең Тын океан флотында хәрби очучы булып хезмәт итә (1941-1945), япон империалистларына каршы сугышларда катнаша, шәхси батырлыклары өчен сугышчан медальләр белән бүләкләнә. Шагыйрь, прозаик һәм драматургның балаларга атап язылган, әхлак-этика мәсьәләләрен чагылдырган “Очучы язмалары” әсәре шәхси кичерешләренә нигезләнеп язылган. Дошманга каршы нәфрәтнең һәр очучы күңелендә иң изге төшенчәләргә бәйле рәвештә формалашуын автор зур осталык белән күрсәтә. Язучыны үз геройлары мисалында аларга хас югары әхлакый сыйфатларны, гуманлыкны, дуслык хисләрен вакыйгалар барышы гына түгел, ә кешенең сугышта үз-үзен тотышы, кылган эшләренә җаваплылык хисенең нинди дәрәҗәдә булуы кызыксындыра.

Язучы, тәрҗемәче Ибраһим Гази (1907-1971) 1943 елдан башлап җиңү көннәренә кадәр хәрәкәттәге армия сафында, фронтта чыга торган “Сталин байрагы”, “Кызыл Армия” газталарында хәрби корреспондент булып хезмәт итә, шундагы кырыс шартларда күпсанлы очеркларын, хикәяләрен яза. Сугыш вакытындагы “Куен дәфтәреннән” язмалары оста каләм белән иҗат ителгән. Сугыш шартлары булуга карамастан, иптәшләрчә юмор, шаянлык әсәрне бизи. Табигать матурлыгын табарга тырыша, берничә минуттан бу гүзәллекнең бетәчәгенә күңеле әрни: “1942 ел. Яз Җир ачылган; анда-санда тирән чокырларда, кипкән елгаларда гына агарып кар күренә. Ашыгып гөрләвекләр ага; тургай сайрый; җирдән җылы пар күтәрелә; кара каргаларның моңлы тавышлары ишетелә...кырда кояш астында атлар йөри; төнлә кибеп өлгергән ермаклардан көндез яңадан шаулы йөгрек сулар ташып ага..”.

Күренекле әдип-прозаик Әмирхан Еникине (1909-2000) бөтен җиһанны үзенә тартып алган сугыш хәрәкәтләре читләтеп узмый. “Мин сугыш вакытында әдәбиятка кайткан кеше. Дәһшәтле авыр елларда күргән-кичергәннәрем моңа сәбәп булгандыр дип беләм. Гомумән, мин үз иҗатымда күбрәк тормышта күргәннәргә яки ишеткәннәргә таянырга тырышам...Әмма

нәрсә турында ничек итеп язуга килгәндә, бу кадәресе минем өчен һәрвакытта намус эше булып кала бирде”. Әдип  сугыш елларында хәрәкәттәге армиянең хуҗалык һәм каравыл частьларында рядовой солдат булып хезмәт итә. “Фронт дәфтәреннән” публицистик язмасында язучының баштан үткәннәре сөйләнелә. Автор укучыны кискен борылышлар китереп чыгарган иҗтимагый вакыйгалар белән таныштыра. Язучыны сугышны булдырмый калып була идеме, алдан әзерлек күреп була идеме? дигән сорау да борчый. Язучы сугыш белән очрашкан тереклекне, кешене сурәтли, сугышның иң куркыныч фаҗига икәнлеген шулар аша гәүдәләндерә. Илдә барган зур югалтуларның нинди дәрәҗәдә тирән булуын аңлата. Ә.Еники яшәү һәм үлем, гаделлек һәм намуссызлык, бөеклек һәм түбәнлек төшенчәләрен дөнья, ил, җәмгыять ил язмышлары белән үлчи: “Сугыш кше табигатенә каршы нәрсә, кеше үләргә теләми, яшәргә тели – мәҗбүр ителгәнгә күрә генә ул үлемгә бара. Әмма мәҗбүр итүчеләр үзләре күп вакытта исән калалар. Кешелек дөньясының олы бер фаҗигасе бу...”. Ә.Еники - Татарстанның халык язучысы, ТР Г.Тукай премиясе лауреаты

Шагыйрь, хикәяче, публицист Шәрәф Мөдәррис (1919-1963**)** 1941 елның язында гаскәри хезмәткә алына һәм сугышның беренче көннәреннән үк алгы сызыкта була, башта минометчы, ахырга таба татар фронт газеталарының хәрби мөхбире сыйфатында сугыш юлын уза, яралана, контузияләр ала, шәхси батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә. “Кайнар көннәр” истәлек-язмасында вакыйгалар мин исемннән сөйләнелә. Биредә Смоленск өлкәсенең бер аэродромында хезмәт иткәндә, йөрәгенә кереп калган, капитан Безбородов турында сүз бара. Язучы портрет алымнарын оста файдалана. Фронт юлларында бөтен нәрсәнең сугыш белән сулавына борчыла. Плакаттагы кулынна мылтык тоткан кызылармеец: “... билендә подсумка, башында каска, йөзендә җитди һәм ачулы сыман төс”. “Син фронтка нәрсә белән ярдәм иттең?” дигән сорау тора. “Бу – хаклы сорау. Бу – сорау да, таләп тә. Бу – наказ да, бурыч та. Бу – һәркемгә, бу һәрвакыт”. Кан белән язылган бу сүзләр һәр сугышчы йөрәгендә. Геройга

төрле госпитальләрдә ятарга туры килә. Автор халык гыйбарәләрен дә кертеп җибәрә, идея ачык чагыла: “Эт күпме генә күккә карап йолдызга өрсә дә, берни эшли алмый. Елан гранит диварга күпме генә башын бәрсә дә тишә алмый”. Әсәрдә геройларның яшәү белән үлем мәсьәләсе хәл ителгән мизгелдә сынала. Бу сынауның нигезендә яшәешнең шушы ике чиге арасында барган мәңгелек көрәш-тартыш ята. Геройларның әхлак көче шушы арада тирбәлә. Кайсы өстен чыгар? Хәлиткеч минутта нинди юл сайланыр? Язучы, авыр ситуациядә калып, яшәү белән үлемнең берсен сайларга тиеш булган кешенең эчке дөньясына керергә омтылыш ясаганда, әнә шундый мөһим әхлакый-социаль проблемага юлыга. Хәмит Сафинның үлем белән күзгә-күз очрашкандагы халәтен, эчке кичерешләрен тасвирлауга зур әһәмият бирә. Бары шул мәлдә генә аның яшәү белән үлем арасында тирбәлгән рухи халәтен аңларга мөмкин. Ватан сугышы геройның рухы, дөньяга карашлары өчен иң авыр һәм җаваплы сынау дип карала.

**Файдаланылган әдәбият**


1. Әгъзәмов Ф. Үзәктә - кеше. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – Б. 68.
2. Әхмәт А. Сайланма әсәрләр.- Казан: Казан: Татар.кит.нәшр., 1964.- 351б.
3. Әпсәләмов Г. .- Казан: Таткнигоиздат.- Матур әдәбият редакциясе, 1954.- 282 б.
4. Баттал Б. Сигезенчесе кем?: Повестьлар.- Казан: Татар.кит.нәшр., 2005.- 175 б.
5. Гази И. Чикләвекләребез төшле булсын: Мәкаләләр, истәлекләр, очерклар һәм көндәлекләр.- Казан: Татар.кит.нәшр., 1984.- 280б.
6. Бәширов Г. Сайланма әсәрләр: 5 т. .- Казан: Татар.кит.нәшр.,2005.- 415б.
7. Еники Ә. Әсәрләр: 5 томда.- 5 том: Публицистик язмалар, мәкаләләр.- Казан: Татар.кит.нәшр., 2004.- 479 б.

8. Иделле Г. Сайланма әсәрләр.- Казан: Таткнигоиздат.- Матур әдәбият редакциясе, 1955.- 177 б.
9. Мөдәррис Ш. Ильич нурлары.- Казан: Казан: Татар.кит.нәшр., 1969.- 284 б.
10. Мөҗәй Х. Сугыш язмалары. Төзүчесе С.Шакир.- Казан: Татар.кит.нәшр., 1968.- 332 б.
11. Шамов А. Чын хикәяләр. Хикәяләр, очерклар, истәлекләр.- Казан: Казан: Татар.кит.нәшр., 1986.- 439 б.